РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
Чалпинского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай
муниципаль районы Чалпы авыл жирлеге
Советы
БАШЛЫГЫ

ул. Центральная, д.39, с. Чалпы, 423324
Азнакаевского муниципального района
Тел. (8-5592) 35-5-46, факс (8-5592) 35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

Үзәк урам, 39, Чалпы авылы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46,
факс (8-5592) 35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» ноябрь 2021 ел № 6

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Ирекле торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Уставының 15.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Чалпы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Ирекле т. п., Гагарин ур., 42 нче йорт адресы буенча урнашкан Ирекле авыл мәдәният йорты бинасында 2021 елның 02 декабрендә 13.00 сәгать 00 минутта Ирекле авылы Гагарин ур., 1 нче йорттан 64 нче йортка, Яңа ур., 1 нче йорттан 9 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегенең Ирекле торак пунктында 2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының беренче этабын** билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Ирекле т. п., Гагарин ур., 42 нче йорт адресы буенча урнашкан Ирекле авыл мәдәният йорты бинасында 2021 елның 02 декабрендә 14.00 сәгать 00 минутта Ирекле авылы Яңа ур., 9 нче йорттан 29 нче йортка, Наратлы ур., 1 нче йорттан 26 нчы йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегенең Ирекле торак пунктында 2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының икенче этабын** билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Ирекле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Ирекле торак пунктында Гагарин, Сосновая урамнары буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (вак таш җәелгән юлларны карап тоту, юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү));

- Ирекле торак пунктында җирлекне яктырту һәм урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтү);

- Ирекле торак пунктында тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәт күрсәтүгә түләү (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү);

- Ирекле торак пунктында халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, килешү буенча түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария ситуацияләрен бетерү, торбаларны алыштыру, ЗСО су чыганакларын төзекләндерү, ЗСО проектларын әзерләү буенча хезмәтләр өчен түләү, эчәргә яраклы суны биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү);

- Ирекле торак пунктында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне»нә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү, сәхнә костюмнары, музыка аппаратурасы сатып алу)

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Чалпы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru ) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге башлыгы ____________ А.М.Мөхәмәтшин
(имза) (имза расшифровкасы)